yulbasma

Абдулла Алиш

# Алиш әкиятләре



Рәссам
Гүзәл Гарипова

УДК 821.512.145
ББК 84 (2Рос=Тат)
А50

Алиш әкиятләре: әкиятләр / Абдулла Алиш [төз. Г. Хәсәнова]. — Казан : «Юлбасма» нәшр., 2023. — 100 б.

Бу китапка балалар язучысы Абдулла Алишның 1938—1939 елларда язылган әкиятләре тупланды. Китап ата-аналарга, балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга, башлангыч сыйныф укучыларына тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-6048800-4-3

## ЭЧТӘЛЕК


Биккуркак белән Бикбатыр 5

Мактанчык Чыпчык белән Тыйнак Сыерчык 17

Бик яхшы сабак алды Ябалак 33

Чукмар белән Тукмар 49

Каз белән Аккош 59

Сертотмас Үрдәк 73



# Бикбатыр белән Биккуркак





Бер баланың ап-ак куяны белән бик матур песие булган. Алар үзара бик тату яшәгәннәр. Куян, кетер-кетер итеп, агач кайрысы кимергән, ә песи, чепер-чепер итеп, сөт эчкән.

Песи бернәрсәдән дә курыкмый икән, аңа теге бала Бикбатыр дип исем кушкан. Куян, дер-дер килеп, бар әйбердән дә шүрләгәнгә, аны ул Биккуркак дип атаган.





Биккуркак беркөнне стенада коточкыч әйбер күргән: колаклары бик озын, мыеклары селкенеп тора, ә үзе бик килбәтсез икән. Куян куркуыннан нишләргә дә белмәгән, баскан урынынннан кузгала да алмаган. Ярый әле Бик-батыр килеп җиткән.



— Әй юләр, юләр, — дигән Бикбатыр, — үз шәүләңнән үзең куркып торасың ич.

— Ярый әле син килдең, Бикбатыр, куркуымнан үлгән булыр идем, — дигән Куян.





Икенче бер вакытны Куян тагын куркуга төшкән, йөрәге дөп-дөп типкән: нәрсәдер бик нык итеп кыштырдый икән.

— Кыштырдаучы нәрсә хәзер идән астыннан чыга да мине кабып йота, — дип



шүрләгән ул. Моңа песи дә колакларын торгызган. «Ул да курка бугай», — дип уйлаган Куян.

Шулчак «шап» иткән тавыш ишетелгән. Куян һушсыз кала язган.